СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 в, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

29.10.2020 с. Печищи №2-15

Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020нче елның 6нчы августындагы 658нче номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи  авыл җирлеге Советының
2018нче елның 25нче апрелендәге
33-159нчы номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге  җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет сәркатибе | 15292 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи  авыл җирлеге Советының
2018нче елның 25нче апрелендәге
33-159нчы номерлы карарына
12нче кушымта

Печищи авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 15759 |

2. Әлеге карар 2020нче елның 1нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Печищи  авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Л. В.  Яковлев